БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«02» 07 2026 ел

**КАРАР**
№ 208

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль милкендә булган гомуми белем бирү оешмаларындагы спорт объектларын укудан тыш вакытта Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан файдалану Тәртибен раслау турында

Балтач муниципаль районының барлык халык төркемнәренең сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга ихтыяҗларын канәгатьләндерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физик культура һәм спорт белән массакүләм, системалы шөгыльләнү, актив яшәү рәвешенә җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Физик культура һәм спортны үстерү Советының 2023 елның 19 октябрендәге Пр-2466 номерлы утырыш йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлегенең 9 пунктындагы «б» пунктчасын, «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына таләпләрне раслау һәм шушы объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты формасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 2 августындагы 1006 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы муниципаль милкендәге гомуми белем бирү оешмаларының спорт объектларын укудан тыш вакытта Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан файдалану тәртибен (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «02» 07
208 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль милкендә булган гомуми белем бирү оешмаларындагы спорт объектларын укудан тыш вакытта Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан файдалану
Тәртибе

1. Балтач муниципаль районы муниципаль милкендә булган гомуми белем бирү оешмаларындагы спорт объектларын укудан тыш вакытта Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан файдалануның әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип) физик культура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнү өчен шартлар тудыру максатында эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы биналарын (мәйданнарын, спорт корылмаларын, ярдәмче биналарны) Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан укудан тыш вакытта файдалану механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә тиешле билгеләмәләре булган түбәндәге терминнар кулланыла:

спорт чарасы - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлеге карамагында булган учреждениеләрнең спорт корылмалары территориясендә һәм эчендә үткәрелә торган теләсә нинди даими булмаган чара;

физкультура-сәламәтләндерү хезмәте - кулланучының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту ихтыяҗларын канәгатьләндерү, гражданнарны физик тернәкләндерү, физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт ялын уздыру буенча башкаручының эшчәнлеге;

спорт хезмәте - спортта нәтиҗәләргә ирешүдә кулланучының ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча башкаручының эшчәнлеге;

хезмәтне кулланучы - сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, югары эшкә сәләтлелекне саклау өчен физик күнегүләр һәм спорт белән шөгыльләнү, актив ял итүнең төрле төрләрендә, спорт-тамаша уеннарында, мәдәни-массакүләм һәм күңел ачу-уен чараларында катнашу теләге булган, төркемнәргә оешкан Россия Федерациясе гражданнары (балалар, яшүсмерләр, өлкән яшьтәге кешеләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һ. б.) һәм юридик зат формасында теркәлгән оешмалар;

укудан тыш вакыт - дәресләр һәм чаралар үткәрүдән буш вакыт, шул исәптән каникул, ял һәм бәйрәм көннәре;

хезмәт күрсәтүче - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

спорт объекты - физик культура дәресләре, спорт юнәлешендәге дәресләр: күнегүләр, спорт уеннары, спорт ярышлары, башка чаралар үткәрү өчен, шул исәптән халыкка физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнү өчен ачык яссы спорт корылмаларына керү мөмкинлеге бирү юлы белән файдаланылырга мөмкин булган объектлар.

3. Учреждениеләр түбәндәге принциплар нигезендә Балтач муниципаль районы халкының физкультура-спорт инфраструктурасыннан файдалану күләме турында мөстәкыйль рәвештә карар кабул итәләр:

3.1. Учреждениеләрнең төп устав эшчәнлеген (тренировка, белем бирү процессын) тулы күләмдә тәэмин итү, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү максатларында файдалану өчен спорт объектларын бирү турында төзелгән шартнамәләрне үтәү кирәклеген исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениеләренең спорт объектларын Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан максималь куллануны тәэмин итү;

3.2. Законнарда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләрен үтәү.

4. Гомуми белем бирү учреждениеләренең спорт объектлары Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан Учреждениеләрнең төп эшчәнлегенә зыян китермичә кулланылырга тиеш.

5. Гомуми белем бирү учреждениеләренең спорт объектларын Балтач муниципаль районы халкы тарафыннан куллану түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

5.1. Учреждениеләрнең локаль норматив актлары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләренең спорт объектларын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү максатларында файдалануга бирү буенча хезмәтләр күрсәтү;

5.2. Физик культура һәм спорт белән мөстәкыйль шөгыльләнү өчен ачык яссы спорт корылмаларына Балтач муниципаль районы халкының керү мөмкинлеген булдыру.

6. Учреждениеләр Балтач муниципаль районы халкының гомуми белем бирү учреждениесендәге спорт объектларыннан файдалану графигын билгели.

7. Чит оешма, физик затлар төркеме спорт чарасы үткәрергә планлаштырган очракта, алар тиешле Учреждение җитәкчесе белән чараның датасын, вакытын һәм үткәрелү урынын 2 атнадан да соңга калмыйча килештерергә һәм Учреждениеләрнең спорт объектларындагы биналарны (мәйданнарны, спорт корылмаларын, ярдәмче биналарны) гражданнар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар тарафыннан куллану өчен Мөлкәт хуҗасының һәм Оештыручының ризалыгы белән гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә бушлай, ташламалы яки түләүле нигездә килешү төзергә тиеш.

8. Балигъ булмаган балаларның оештырылган төркемнәре спорт объекты биналарына өлкәннәр (төркем өчен җаваплы кешеләр) белән исемлек буенча кертелә. Балигъ булмаган балалар төркеме исемлегендә аларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, уку урыны, шулай ук аларны озата баручы төркем өчен җаваплы өлкән кешенең фамилиясе, исеме,

9. Чараны тиешле шартнамә төземичә мөстәкыйль рәвештә үткәрү тыела. Килештерелмәгән чара уздыру факты ачыкланганда тиешле учреждение администрациясе чараны туктатырга һәм анда катнашучыларның барысын да учреждение территориясеннән чыгарырга хокуклы.

10. Учреждение җитәкчеләре Балтач муниципаль районы халкы өчен дәресләр һәм физкультура-спорт чаралары уздыру урыннарының техник торышын техник регламент таләпләре, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары билгеләгән нормалар, кагыйдәләр һәм таләпләр, санитария кагыйдәләре нигезендә тиешенчә тәэмин итәргә тиеш.

11. Спорт объектларына килүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

- объектның функциональ үзенчәлекләрендә каралган хезмәтләрнең барлык төрләреннән файдалану;

- әлеге Тәртип белән тыелмаган шәхси әйберләрне алып керү.

12. Спорт объектларына килүчеләр:

- спорт объектларына, спорт җиһазларына, спорт инвентарена сак карарга;

- спорт объектыннан файдаланганда тәртип сакларга һәм кагыйдәләрне бозмаска;

- конфликтлы хәлләрне кисәтергә, башка затларга карата кимсетүле сүзләр һәм хулиганлык гамәлләре кылмаска;

- спорт объектында булуның куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәү буенча шәхси җаваплылык сакларга тиеш;

- спорт җиһазларының, спорт инвентаренең ватылуы (зарарлануы) ачыкланганда (килеп чыкканда) төзек булмаган спорт җиһазларын, спорт инвентарен куллануны туктатырга һәм бу хакта объекттан файдалануны оештыру өчен җаваплы юридик затның вазыйфаи затына кичекмәстән хәбәр итәргә кирәк.

13. Спорт объектларыннан файдаланганда түбәндәгеләр тыела:

- спиртлы эчемлекләр эчү, тәмәке, наркотик яисә психотроп матдәләр куллану;

- территориягә корал (спорт коралыннан тыш), шартлаткыч, тиз янучан матдәләр һәм материаллар алып керү, ә спорт мәйданчыгы территориясенә пыяла савыт-саба алып керү;

- гамәлдәге закон таләпләрен бозып пиротехник эшләнмәләр куллану;

- учак ягу;

- хайваннарны йөртү;

- җитештерү һәм куллану калдыкларын моның өчен билгеләнгән урыннардан читтә урнаштыру;

- спорт өслегенә сыеклыклар түгү;

- спорт өслегенә зыян китерү;

- зарар китерү (шул исәптән язулар), спорт җиһазларын, спорт инвентарен, кече архитектура формаларын тиешенчә кулланмау;

- реклама турындагы закон таләпләрен үтәмичә спорт җиһазларына реклама беркетү;

- объект территориясендә шөгыльләнүче башка кешеләргә берә торып

14. Учреждениеләр, спорт объектлары халык тарафыннан кулланылганда спорт объектында куркынычсызлык таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәләр.